Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Апак авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2019 нчы елның 15 нче апреле 7 №

Һөнәри керемгә салым буенча салым
потенциалын үстерүне стимуллаштыру
максатларында алынган башка бюджетара
трансфертлар акчалары исәбеннән гамәлгә
ашырыла торган чыгымнарны җибәрү турында.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.03.2019 ел, №233 карары белән расланган муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 7 пункты нигезендә Әлки муниципаль районының Апак авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1 нче Статья.

Һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалы үсешен стимуллаштыру максатларында түбәндәге чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итүгә алынган башка бюджетара трансфертлар хисабына гамәлгә ашырыла торган чыгымнар юнәлешен расларга:

1) җирлекнең муниципаль милкендәге мөлкәте белән идарә итү, файдалану һәм эш итү;

2) җирлек торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;

3) җирлек халкын элемтә, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

4) җирлек халкын ял итү һәм хезмәт күрсәтү өчен шартлар тудыру;

5) җирлек территориясендә физик культура, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;

6) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

7) адресация объектларына адреслар бирү, адресларны үзгәртү, бетерү, урам-юл челтәре элементларына исем бирү(федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, муниципаль районның җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш), авыл җирлеге чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исем

бирү, шундый атамаларны үзгәртү, бетерү, мәгълүматны Дәүләт адреслы реестрында урнаштыру;

8) авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерүгә ярдәм итү, кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен шартлар тудыру;

9) җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм тормышка ашыру;

10) җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә ярдәм күрсәтү, халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыру;

11) каты коммуналь калдыкларны транспортировкалау һәм җыю (шул исәптән аерым җыю) эшчәнлеген оештыруда катнашу;

12) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;

13) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, су бүлү, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

14) җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

15) милләтара һәм конфессияара килешүне ныгытуга, җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә, мигрантларны социаль һәм мәдәни адаптацияләүгә, милләтара (этникара) низагларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

16) җирлек халкы күпләп ял итә алсын өчен шартлар тудыру һәм халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми кулланылыштагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына иркле үтеп керүен тәэмин итү дә.

2 нче Статья.

Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә.

Әлки муниципаль районы
Апак авыл җирлеге Советы рәисе Әбҗәббәрова И.Х.